Мөслим районы газетасы
Татарстан Республикасы
Чәршәмбе
№ 83 (11335)
**11 ноябрь** 2020 ел
Газета 1931 елдан бирле чыга 16+

# Авыл утлары

**БЕЗ – МӨСЛИМЛЕЛӘР!**
**Сельские огни**

Район яңалыклары – безнең сайтта **www.muslumirc.ru** һәм социаль челтәрләрдә

# Безнекеләр 100 балл җыйды!

5 ноябрьдә "Мизгел" яшьләр үзәгендә узган онлайн-диктантта җирлегебездәге төрле милләт берләшмәләре вәкилләре – 30га якын кеше катнашты.



Этнодиктант язу мизгелләре./ ЛИЛИЯ ШӘЙМИЕВА ФОТОСЫ.

Актуаль!

**Лилия Шәймиева**

**3-8 ноябрь көннәрендә республикада "Зур этнографик диктант" халыкара акциясе узды. Бишенче ел рәттән оештырылучы акциянең төп яңалыгы – аның онлайн-форматта үтүе. Өч ел элек диктантны БДБ илләрендә һәм ерак чит илләрдәге ватандашлар да яза башлады.**

Узган ел чарада 5 мең кеше катнашкан булган. Диктантны оештыручылар хәбәр итүенчә, пандемия шартларында милли бәйрәмнәр дә онлайн форматта узды. Чара биш көн дәвам иткәч, катнашырга теләүчеләрнең саны да арткан.

– Мөслимдә этнографик диктант язарга теләүчеләр саны күп булды. Онлайн оештырылуы да яхшы алым дип уйлыйм. Татарстан Республикасы халыклары ассамблеясенең Мөслим районындагы вәкиллеге урнашкан "Мизгел" яшьләр үзәгендә диктант язу өчен махсус пункт оештырылды. Аерым төркемнәр бередә үзләренең белемнәрен сынады. Этнографик диктантта 30 сорау бирелде, җаваплары да күрсәтелде. Диктант язучы дөрес җавапны сайлап алырга тиеш иде, – ди район иҗтимагый советы рәисе Рушат Солтанов.

Диктант сораулары Россиядә яшәүче милләтләрнең гореф-гадәтләренә, мәдәниятләренә кагылышлы иде. Сорауларга дөрес җавап бирү төрле милләт вәкилләренең үзара мөнәсәбәтләрен, йолаларын аңлап, ихтирам итеп, берләренә тагын да якынаеп яшәргә ярдәм итүдән гыйбарәт иде.

– Мин мондый чараларда һәркем катнашырга тиеш дип уйлыйм. Рус Шуган җирлегеннән дә шактый кеше катнашты. Үзем дә сынау тоттым. Имтиханны уңышлы тапшырдым дип уйлыйм, – диде "Мизгел" яшьләр үзәге җитәкчесе Вадим Харитонов.

Быел этнодиктант нәтиҗәләре онлайн-режимда мөстәкыйль рәвештә ясалды. Йөз мөмкинлектән йөз балл җыючылар да күп булды. Диктант язып бетерү белән нәтиҗәләр билгеле булды. Катнашучыларның барысы да имтихан тапшыру турында сертификат алды.

– Бу чарадан читтә кала алмадым – онытым Камил белән диктант яздык. Үзебез өчен бик күп мәгълүмат алдык, яңалыклар белдек. Россия халыкларының үзенә хас традицияләре, көнкүрешләре гаҗәеп бай мирас бит ул. Сорауларның барысына да уңышлы җавап бирә алдык, – ди Мөслимдә яшәүче Рәзинә Исламова.

**Быел 11 илдә зур этнографик диктант язганнар. 2018 елдан башлап этнодиктант "2025 елга кадәр чорга дәүләт милли сәясәте стратегиясе"н тормышка ашыру планына кертелде.**

2021 ЕЛНЫҢ БЕРЕНЧЕ ЯРТЫЕЛЛЫГЫНА «АВЫЛ УТЛАРЫ» ГАЗЕТАСЫНА ҺӘМ БЕР ЖУРНАЛГА ЯЗЫЛЫП

**КАР КӨРИ ТОРГАН МАШИНА, КУХНЯ ТЕХНИКАСЫ ҺӘМ ГАДЖЕТЛАР ОТ!**

**Катнашу шартлары**

- 2020 елның 25 декабренә кадәр «ТАТМЕДИА» АҖнең бер газета һәм бер журналына языл (акциядә катнашучы басмалар белән tatmedia.ru сайтында танышып була)
- «Акция» билгесен куеп, язылу квитанцияләренең копиясен безгә җибәр (телефон номерыгызны язарга онытмагыз). Адрес: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 яки podpiska@tatmedia.ru

Тулырак мәгълүматны, акциянең узу вакытын, бүләкләр, аларны алу тәртибе турында tatmedia.ru сайтында белә аласыз. Акция 19.10.20 — 20.03.21 кадәр үткәрелә. Гаризалар 30.01.2021 кадәр кабул ителә. Оештыручы — ТАТМЕДИА АҖ. Реклама 16+ Товарлар рәсемдә күрсәтелгәннән үзгә булырга мөмкин.




## Хәбәрләр

**Хезмәтен хөрмәтләп**

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, авыл хуҗалыгы үсешенә керткән лаеклы өлеше өчен һәм 80 яшь тулу уңаеннан агросәнәгать комплексы ветераны **Гаязова Гөлсинә Фәтхулла кызы** ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Рәхмәт хаты белән бүләкләнде.

**Демография – саннарда**

**Районның гражданлык хәле актларын теркәү бүлегеннән алынган мәгълүматлардан күренгәнчә, октябрь аенда җирлегебездә 2 кыз һәм 6 малай туган.**

Ел башыннан туучылар саны 99ны тәшкил итә. Октябрь аенда 34 кеше якты дөнья белән хушлашкан. Аларның 12се – ир-ат, 22се – хатын-кыз. Ел башыннан үлүчеләр саны – 305. Узган айда 7 пар никахларын рәсмиләштергән. Ел башыннан 75 пар гаилә корган, 4 пар аерылышкан. Тугыз айда 51 гаилә таркалган.

**Сакланганны саклар**

**Район үзәк хастаханәсенә август аеннан башлап бүгенге көнгә кадәр грипкка каршы 6661 доза вакцина кайтты.**

Аның 4382е – зурлар өчен, калганы – балаларга. Зурлар өчен кайткан "Совигрипп" һәм "Флю-М" вакциналарының 80 процентка якыны кадалган. Балалар өчен булганының 85 проценты ясатылган. Табиблар әлеге вакциналарның вирусы грипп авыруларын кисәтүдә һәм авырган очракта җитди катлауланулар булдырмауда зур роль уйнавын искәртә. Теләүчеләр поликлиникага барып, грипкка каршы вакцина ясата ала.

**Сессия була**

2020нче елның 13 ноябрендә Мөслим муниципаль район Советының утырышлар залында дүртенче чакырылыш Мөслим муниципаль район Советының II сессиясе була. Башлана 10.00 сәгатьтә.

## Һава торышы

**Чәршәмбе** 11.11
-2 **-4**

**Пәнҗешәмбе** 12.11
-4 **-1**

**Җомга** 13.11
-3 **-8**

**Шимбә** 14.11
-8 **-13**

«Авыл утлары»
№ 83 (11335) | **11 ноябрь** 2020 ел

Яңалыкларны беренче булып
**www.muslumirc.ru** сайтында укыгыз

Бу көнне Мөслимдә

## 1985 ел

**31 октябрь**
**Мактаулы безнең бурыч**

Мин хезмәт куя торган тегү цехына килгәндә дә, уңай яктан күрсәтеп үтәрлек эшләр бар. Тугыз айда безнең коллектив халыкка 32564 сумлык хезмәт күрсәтте. Мин инде ел башыннан ук киләсе бишьеллык исәбенә эшлим.

Казаннан тәҗрибәле модельерлар китертеп, безне тегүнең яңа алымнарына өйрәтү матур гадәткә керде. Идарә направлениесе белән бүгенге көндә алты кеше Казан һәм Брежнев шәһәрләрендәге училищеларда – тегүчелеккә, өч кеше телевизор һәм көнкүреш техникасы ремонтлау мастерлыгына укый. Үзебезнең комбинатта ике иптәш өйрәтелә.

Киләсе елда һәйкәл ясау цехы ачу, туй хезмәте күрсәтүнең эчтәлеген тирәнәйтү, аяк киемнәрен үзебезнең материалдан тегү, квартирлар ремонтлау бригадасы оештыру күздә тотыла.

**М. Вагыйзова, халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү производство идарәсе тегүчесе.**

**7 ноябрь**
**Энергетиклар өлеше**

"Сельхозэнерго"ның хуҗалыкара район производство-энергетика берләшмәсе бәйрәмне уңышлар белән каршылый. Быел тугыз айлык план 103 процентка үтәлде. Берләшмә эшчеләре колхоз-совхозларда намуслы хезмәт куя. Алар терлек торакларындагы, гомумән, хуҗалыктагы барлык электр җиһазларын көйлиләр.

**Т. Нәсифуллина, профсоюз комитеты председателе.**

**12 ноябрь**
**Активлык җитми**

М. Горький исемендәге колхозның иң зурлардан саналган Октябрь бригадасы комсомол оешмасы кырыктан артык ВЛКСМ членын берләштерә.

Бүген бирегә яшьләр комсомол тормышында ел дәвамында булган үсеш-үзгәрешләр әле тәэтелеп җитмәгән җитешсезлекләр, киләчәккә бурычлар хакында сөйләшергә җыелдылар. Әмма комсомоллар авызларына су капкандай, тыныч кына утыра бирделәр. Күзләрен трибунага төбәп тыныч кына утырган егетләрнең һәм кызларның һәрнәрсәгә битараф калуы гаҗәпләндерде.

**Л. Каһарманова, махсус хәбәрчебез.**

***Сәхифәне Мөнирә Арсланова әзерләде.***

# Иминлек үзебездән тора

## Спиртлы эчемлекләр куллангансың икән, руль артына утырма. Шәхси мәгълүматларны башкаларга бирмә!



Район эчке эшләр бүлеге җитәкчесе Р. Гатауллин./ФОТО – "МӨСЛИМ-ИНФОРМ" АРХИВЫННАН.

Кеше һәм закон

**Лилия Шәймиева**

**Районда оператив хәл стабильме? Халыкны бүгенге көндә нәрсә кызыксындыра, ни борчый? Шушы һәм башка сорауларга район эчке эшләр бүлеге җитәкчесе Раил Гатауллин җавап бирә.**

**– Раил Равилевич, җирлегебездәге оператив хәл белән таныштырсагыз иде.**

– Быел 9 айга 109 җинаять теркәлде. Узган ел бу сан 99 гына иде. Аерым юнәлешләр буенча алсак, былтыр яшерен урлау очраклары өч тапкыр арткан иде. Быел урлау очракларын туктата алдык. 2020 елның тугыз аенда 36 җинаять очрагы теркәлде. Соңгы арада мошенниклар дистанцион форматта эшли башлады. Моның өчен алар кәрәзле телефоннар, интернет челтәрен эшкә җигә. Ел башыннан әлеге төрдәге 8 җинаять эше теркәлде.

**– Мошенниклар ничек эш итә? Мошенниклар кармагына кемнәр ешрак каба?**

– Иң элек мошенниклар зыян күрүче белән элемтәгә керәләр һәм аның шәхси мәгълүматларын җыялар. "Банк картасының мәгълүматларына тәэтмә кертәбез" яисә "Сезнең исемгә кредит алганнар, аны юк итәбез" дип, бик күп уйдырмалар белән банк картасы мәгълүматларын сорыйлар. Банк хезмәткәре беркайчан да телефон аша мәгълүмат алмый. Мондый мәгълүматларны җинаятьчеләр генә сорый ала. Банк картасы мәгълүматларын бирергә ярамый.

Алдарлар ятьмәсенә кабучылар арасында өлкән яшьтәгеләр һәм эш яшендәгеләр беренче урында тора. Республика буенча мошенниклардан бер атнада килгән зыян күләме 40-50 млн сумнан артып китә һәм ун җинаятьнең икесе ачыла. Районда ике җинаять эшен ача алдык. 2019 елда бер райондашыбызның шәхси мәгълүматларын кулланып, кредит алганнар иде. Җинаятьченең эзенә төшеп, сумманы кире кайтардык. Икенче очракта Кемерово шәһәренә кадәр барып җиттек. Эш судка китмәде, чөнки җинаятьче – 15 яшьлек үсмер! Балигъ булмаганнарны җинаять җаваплылыгына тартып булмый. Мошенникларны ачыклавы бик кыен, чөнки урланган акча, бер счеттан икенче счетка күчә-күчә, әллә кайларга барып җитә. Мисал өчен, бер очракта телефон номеры Украинада теркәлгән булып, акча Яр Чаллы, Казан, Краснодарга киткән.

**– Алдарлар кулына эләкмәс өчен нинди киңәш бирер идегез?**

– Шәхси мәгълүматларны чит кешегә бирергә ярамый. Интернетта уяу булыгыз. Бушлай сыр тәбедә генә була. Бер очракка тукталам: начар кредит тарихы булганнарга кредит алырга ярдәм итәбез" дигән сүзләргә ышанып, акчасыннан колак кага. Икенче берәү, хөкүмәтнең бушлай ярдәм бирәсенә ышанып, шулай ук акчасыз кала. Мошенниклар корбаны булмас өчен, киңәш сорап, участок инспекторларына мөрәҗәгать итәргә була.

**– Балалар арасында хокук бозу очракларына тукталсагыз иде.**

– Сәүдә нокталарында вак урлау очраклары теркәлде. Гадәттә, балалар үзләре кызыккан әйберләрне кесәләренә салып чыга. Андый хәлләрдә күзәтү камералары ярдәмгә килә. Балалар, үсмерләр катнашында мөлкәтне җимерү очраклары да күзәтелә. Андыйлар белән профилактик чаралар алып барабыз.

**– Раил Равилевич, юллардагы вәзгыять нинди? Исерек шоферлар – баш бәласе. Андыйларга карата нинди чаралар күрелә?**

– Алкогольле эчемлек кулланган хәлдә руль артына утыручылар арасында гади халык белән бергә җитәкче урыннарда эшләүчеләр дә бар. Районның ЮХИДИ инспекторлары исерек шоферларны даими тоткарлап тора. Республика күләмендә безгә карата тәнкыйть гадел булды. Узган ел аварияләрдә үлем очраклары юк иде. Быел 14 юлтранспорт һәлакәте теркәлеп, аларда 5 кеше вафат булды, 17 кеше авыр тән җәрәхәтләре алды. Дүрт авариянең исерек шоферлар аркасында килеп чыгуы мәгълүм.

**– Димәк, аварияләрдә тән җәрәхәтләре алу очраклары да арткан?**

– Өч очракта аварияләр тизлекне дөрес сайламау белән бәйле. Юлда иминлекне саклау өчен профилактик рейдлар үткәрәбез. Ләкин моның өчен ДАИ хезмәткәре генә әз. Районда намуссыз машина йөртүчеләр белән көрәшү өчен Telegram-каналда "Муслюмово пьяный водитель" төркеме булдырылды. Исерек шоферлар турында мәгълүматлар аноним рәвештә кабул ителә. Ни кызганыч, исерек шоферлар саны кимеми. Ике атнада исерек хәлдә машина белән идарә иткән 7 шофер тоткарланды. Алар 1,5 елга машина йөртү таныклыгыннан мәхрүм ителә һәм 30 мең сум штраф та түли. Икенче кат эчеп эләккәндә, җинаять җаваплылыгы каралган.

# Үз-үзеңне дәвалау – куркыныч!

Сәламәтлек

**Әлфинур Ногманова**

**Коронавирус инфекциясе белән авыручылар арасында үз-үзләрен дәвалаучылар арта бара. Бу хакта "Татар-информ" мәгълүмат агентлыгында ТР Сәламәтлек саклау министрлыгы вәкилләре һәм журналистлар белән узган матбугат конференциясендә әйтелде.**

– Пандемиянең икенче дулкынында, ягъни көзен халыкның актив төстә үз-үзләрен диагностикалавы һәм дәвалавы күзәтелә. Коронавирус белән авырган якыннарыннан сорап белгән дәвалау схемасын әйләнә-тирәдәгеләргә тараталар, – ди ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының баш терапевты Диана Абдулганиева.

Министрлык вәкиле үз-үзеңне дәвалауның тормыш өчен куркыныч булуын искәртте. Чөнки бу чир төрле кешедә төрлечә уза. Табиблар белдерүенчә, җиңел формадагы коронавирус инфекциясен дәвалауда гына да өч төрле схема кулланыла. Яңа коронавирус авыруын дәвалауда федераль дәрәҗәдә рәсми теркәлгән дарупрепаратларны билгеләү мөһим. Моны табиб кына хәл итә. Чөнки шикәр диабеты, йөрәк, үпкә һәм югары кан басымы авырулары булучылар кабул иткән дарулар covid-19 вирусына каршы препаратларны кабул иткәндә авыр нәтиҗә күзәтелергә мөмкин, ди табиблар. Вирус йоктырганнан соң күзәтелгән югары температураны төшерүдә глюкокортикостероидлар (стероид гормоннар) куллану да куркыныч булуын искәртә белгечләр. Чөнки алар коронавирус инфекциясенең күпләп үрчүенә китерә икән. Очрашуда авыруны кисәтү һәм дәвалау максатында нинди дару-препаратлар кулланырга икәнен даруханә фармацевтларыннан түгел, табиблардан белешергә киңәшләре искәртелде.

Россия Сәламәтлек саклау министрлыгының Идел буе федераль округында йогышлы авырулар буенча штаттан тыш баш белгече Ирина Кравченко сүзләренә караганда, дөньяда, шул исәптән республикада да covid-19ның авыр формасы белән чирләүчеләр күп мөрәҗәгать итә башлаган.

– Проблеманың төрле аспектлары бар. Беренчедән, вирус үзгәреп тора. Авыручыларның үз-үзләрен дәвалау белән шөгыльләнүе әйләнә-тирәдәгеләрне күпләп зарарлый. Грипп сезоны башлану да авырлык тудыра. Шуңа күрә ОРВИ билгеләре күренү белән табибка мөрәҗәгать итәргә кирәк, – диде Ирина Кравченко.

Белгечләр ассызыклаганча, авыруны вакытында диагностикалау коронавирусның катлаулы формасыннан саклап калырга, эпидемиягә каршы чаралар үткәрергә мөмкинлек бирә, инфекциянең гаиләдә, хезмәт коллективларында таралуына чик куя.

"Вирусның организмга керү юллары – авыз һәм борын куышлыгы. Аларның санитар торышын яхшы тотсагыз, авырмассыз", – диде Сәламәтлек саклау министрлыгының баш пульмонологы Александр Визель. Спикер битлек һәм перчаткалардан йөрергә киңәш итте.

– Урамнан яки эштән кайту белән битлекне салып ташларга, кулларны юарга, авыз-борынны чайкарга кирәк. Күп тапкыр кулланылучы битлекләрне югары температуралы суда юарга. Бер тапкыр кулланыла торганнарын вакытында ташларга кирәк. Дөрес кулланылмаганда, битлек инфекция тарату чыганагы булырга мөмкин, – дип искәртте спикер.

**Табиблар белдергәнчә, яңа коронавирус инфекциясенең авыр формасы булганда тән температурасы 38 градустан югары күтәрелә, сулыш алу авырлаша, тәм һәм ис сизмәү күзәтелә.**

# Төкермә коега!

Кайтаваз

**Минем бу язмам белән кайбер кешеләр килешмәскә дә мөмкин. Бер бәләкәй генә авылда ятып, ни беләсең дә ни күрәсең, диючеләр дә булыр. Булса булыр! Чып-чын татар районы булган Мөслимдә шундый вәхшилекләр эшләнүенә әрнеп язуым.**

"Авыл утлары" газетасында әледән-әле район үзәгендә вандализм күренешләре турындагы язмалар очрап тора. Бу уңайдан актив хәбәрче Флера апа Дәүләтшинаның ачынып язган берничә язмасы чыкты. Журналист Лилия Шәймиева да бу темага берничә тапкыр тукталды. Газетабызның 71нче санында (25.09.2020) Л. Шәймиеваның "Тәрбияләргә соңламагыз!" дигән язмасын укыгач та, кулыма каләм алып, фикерләремне язарга җыенган идем дә вакыт җиткереп булмады. Менә, соң булса да уңбулсын дип, язарга булдым әле.

Матурлыкка, тәзеклеккә, чисталыкка әчләре пошкан кешеләр булыр икән! Без бу дәрәҗәгә бик соң ирештек шул. Мондый авыл, район үзәкләре Балтик буе республикаларында узган гасыр урталарында ук бар иде бит!

1983 елның март аенда ирем белән ике атналык сәяхәттә булып кайттык. Үз гомеремдә беренче һәм бердәнбер сәяхәт булгангамы, әле бүген дә шул вакытта алган тәэсирләрдән арынып булмый. Сәяхәтебез башкалабыз Казаннан башланып, Мәскәү-Ленинград, Минск, Балтик буе республикалары Латвия, Эстония, Литва да дәвам итеп, бик җылы хисләр генә калдырган иде. Төркемдә утыздан артык кеше иде. Балтик буе республикаларындагы тәртип, чисталык, матурлык, тәзеклеккә шаклар катып йөрдек. Литвада безне Тракай шәһәренә алып бардылар. Тракайдан Вильнюска – 27 чакрым. Ул – күлләр белән әйләндереп алынган ярымутрауга урнашкан кечкенә шәһәр һәм район үзәге. Мәйданы – 11,52 квадрат километр, 2019 елгы исәп буенча 5400 кеше яши. Төп милләте – литвалылар (67%). Ел әйләнәсе туристлар агыла бу шәһәрчеккә. Чөнки ул бик чиста, матур, тәзек һәм табигатьнең бик үзенчәлекле почмагына урнашкан. Ул күлләре (200 күл) һәм готика стилендәге утрау замогы белән данлыклы. Гальве күле утрасындагы Тракай замогында без дә булдык. Бу замокта тарихи музей бар. Шуның бер өлеше татарларга багышланган. Чөнки монда татарлар, XIV гасырда Алтын Урдадан качып килеп, кенәз Витовтка хезмәткә урнашып калганнар. Бүгенге көндә дә Тракайда 0,59% татар яши икән. Татарларны бик хөрмәт итәләр монда.

"Өч көн үткәч, исәнме, кодагый!" дигән кебек булса да, юкка искә төшермәдем әлеге сәяхәт мизгелләрен. Шунда йөргәндә:

– Болар ничек кесәләрендәге, кулларындагы чүпләрен җиргә ташламыйча чыдыйлар микән?! Их, бездә дә булсын иде шундый матурлык, чисталык! – дип кызыгып, ак көнләшү белән көнләшеп йөргән идем урамнарыннан.

Бер мин генә булмаганмын икән болай уйлаучы. Туристлар бергәләп җыелганда, барысы да шул фикердә булуларын белдерде. Март уртасында анда бер кар да калмаган иде инде. Әмма һәр җирдә идеаль чисталык хакимлек итә! Бездә исә язын кар астыннан вагонлап төргәрлек чүп чыга! Латвия, Эстониядә дә шундый ук тәртип, чисталык күреп сокланып йөрдек.

Менә хәзер Мөслимебез дә Европаның кечкенә шәһәрләрен хәтерләтә. Моны мин генә әйтмим. Көннән-көн матурлана, яңара Мөслим! Үзәк халкы да бик тырышып яши дип уйлыйм мин. Карагыз сез ул йортларны, ихаталарны! Халык берсеннән-берсе уздырып төзелеш алып бара. Йорт тирәләре агачка, чәчәккә күмелгән!

Үсеп утырган агачны төбетамыры белән йолкыпату, матурлык символы булган чәчәкне ботарлау кемгә кирәк икән?! Безнең буын балаларын әбибабайлар: "Агачлар, чәчәкләр Аллаһы Тәгаләгә зекер (мактау) әйтеп утыралар, аларны тиктомалдан сындырырга, өзәргә ярамый", – дип өйрәтәләр. Шул эшне өлкән яшьтәге кешеләр эшләвенә күңелнең ышанасы килми. Бу матурлыкны тудыруга кемнәрнеңдер зур хезмәте кергән бит. Кеше хезмәтен, авыр хезмәтне бәяли белергә дә кирәк һич югы. Җир казып, билен бөгеп матурлык тудыручыларның ни гаебе бар?!

Район үзәгендәге сугышчан һәм хезмәт даны мемориаль комплексындагы хәлләр турында ишеткәч, бөтенләй әрнедем. Һәйкәлләр – зиратлар кебек үк, изге урыннар бит алар! Ата-бабалар рухы рәнҗүеннән дә курыкмаучы затлар күбәйде. Хәерле булсын! Бу җинаятьне белеп, алдан әзерләнгәннәр кебек! Бәлки кемнәрнеңдер кулы да уйнагандыр...

– Их, сез, балалар, ни эшләгәнегезне беләсезме, аңлыйсызмы?! – дип оран саласы килә! – Сугышның ни икәнен аңламыйсыздыр әлегә. Аның бер сәгате генә дә гасырга тиң, диләр бит сугыш күргән кешеләр. Үлгәннәрнең җаннарын рәнҗетмәгез, зинһар! Ил азатлыгы өчен сугышып һәлак булучылар – шәһитләр алар, изгеләр! Шуны аңлагыз! Ходайның каһәреннән куркыгыз!

"Мы из будущего" (2008 ел) фантастик фильмын карамаган яшьләр сирәктер, дип беләм. Карамаган булсагыз, интернет аша булса да карагыз әле! Бик гыйбрәтле фильм! Вакыт буенча сәяхәт турында ул. Хәзерге заманның кәттә егетләре – Борман, Череп, Чуха, Спирт кушаматлы "черный копатель"ләр бер көнне йөзеп чыгып, 1942 елга – Ленинград фронтына – авыр оборона сугышлары барган участокка килеп эләгәләр... Егетләр могҗиза белән XXI гасырга – үзләре яшәгән чорга әйләнеп кайталар, әмма зур сабак алып. Тормыш ул – бумеранг! Һәр яхшылык та, начарлык та үзеңә кайта. Төкермә коега – суын үзең эчәрсең, ди бит халкыбыз!

*Мәңгелек ут янып тора мәйданда,*
*Тукта, иптәш, шуннан*
*узып барганда.*
*Сал башыңнан бүрегеңне, тынып кал.*
*Ут түгел бу – янып торган изге кан!*
*(Нәби Дәүли)*

**Гөлфия Мөхәммәтгәрәева.**
**Тегермәнлек.**

# Бабайга кунакка баргач

Безгә язалар

**Актаныш районы Әнәк авылында республиканың беренче президенты Минтимер Шәймиевкә ачылган бюстны һәм паркны караргa бардык. Экскурсовод Ильвина Нуретдинова бик ачык йөзле, паркның бөтен җирен күрсәтеп, безне кызыксындырган сорауларга җавап биреп йөрде.**

Бу сукмаклардан – яр эченнән безгә күп йөрергә туры килде. Без бәләкәй чакларда шул ярны чыккач та бик көчле базар була иде. Әткәй-әнкәйләрне базарга җибәрмәделәр. Шуңа күрә миңа йөрергә туры килде.

Ул вакытларда колхозлар көнбагыш чәчте. Уңышын җыйгач та җирдә көнбагыш күп кала иде. Шуларны җыябыз да, башын суктырып киптергәннән соң, базарга алып китәбез. Базарда көнбагыш күп, бездән алмыйлар. Шуңа күрә Пучының Калинин урамында яшәүче Насретдин бабайга бик очсыз хакка гына сатып кайтабыз. Көнбагыш сабагы да файдалы булды. Аны утын урынына кар яуганчы ташыйбыз, ул бик яхшы яна иде.

Пучы район үзәге булгач, ул юлдан күп йөрергә туры килде. Ул елларда юллар юк, язын-көзен баткак була иде. Минтимер Шәймиевнең әтисе Шәрип ага бик ачык йөзле кеше булып, без аларга су эчәргә керәбез. Аны бар халык ихтирам итте.

Бервакыт Пучыдан кайтып барам. Ноябрь ае, кичкә калынды. Шәрип ага мине күреп туктатты да: "Кайда кайтасың, бик соң бит?" – диде. Хәлгә керүче булгангамы, күңелләр тулып китте. Шәрип ага: "Көтеп тор", – диде дә өенә кереп китте, бер телем ипекәй алып чыкты. Безнең ипи күргән бармыни?! Сөенүләрем шул чакта! Шул арада ат белән бер егет килеп җитте (күрәсең, Шәрип абыйларда ул вакытта ук телефон булган). "Менә бу баланы Исәнсеф авылына илтеп кайт", – диде абзыем. Ялгышмасам, Әнәк авылының ул егете Әхтәм исемле иде. Аның Сабантуйларда атлар чабышында катнашканын беләм. Аның белән күп еллар аралашып йөрдек. 1959 елның октябрь аенда Калинин районын бетерделәр. Шуннан соң безнең аралар өзелде.

Минтимер Шәймиев Президент булгач, районны кире кайтарыр дип бик өметләнгән идем. Пучы безгә 8 км гына бит. Анда җәяү дә барып кайтып була иде. Безнең Исәнсеф юлына асфальт салырга да ярдәм итәр дип уйлаган идем. Ике тапкыр хат та яздым. Ул хатны аңа күрсәтмәгәннәрдер инде. Казанга баргач, янына кереп сөйләшмәкче дә идем, кертмәделәр генә.

"Бабайда кунакта" булганда мин әнә шулай үткәннәрне хәтердә яңартып, моңсуланып та йөрдем.

**Мөҗәһидан Мортазин,**
**Исәнсеф авыл җирлеге ветераннар советы рәисе.**

# Бездә шундый хәлләр бар

**Данил Госманов,**
**Мөслим районы хәрби хәрәкәт ветераннары оешмасы җитәкчесе:**

– Күптән түгел генә районга Тукай районының хәрби хәрәкәт ветераннары иҗтимагый оешмасы җитәкчесе һәм районның музей директорлары килде. Алар туган як музее экспозицияләре белән таныштылар. Билгеле инде, әфган сугышына бәйле экспонатлар янында озаккарак тукталдылар. Батырлар йортында исә сугыш чоры вакыйгаларының бирелеше белән кызыксындылар. Тукай районы Иске Абдул авылындагы "Гиндукуш" иҗтимагый-патриотик музеен тәэүчеләр буларак, кунаклар үз тәҗрибәләре белән да уртаклашты.

Әфган сугышы бездән ерагайса да, утлы еллар белән бәйле вакыйгалар онытылмый. Соңгы елларда әфганчылар хәрәкәте дә активлаша бара. Тукай районы әфганчылары башлап җибәргән акциягә кушылдык. Ут эченнән исән кайтып, тыныч тормышта вафат булган әфганчылар истәлегенә алар яшәгән йортларга истәлек такталары куябыз, укучылар белән очрашулар үткәрәбез. Максатыбыз – үсеп килүче яшь буынга хәрби-париотик тәрбия бирүгә үз өлешебезне кертү.

**Ләйсән Әхмәтова,**
**Мөслим:**

– Пандемия чорында бушап калган мәдәният учакларына әкренләп "җан кереп" алды. Район мәдәният йортында Фирдүс Тямаев ике көн рәттән концерт куйды. Ерак дип тормаганнар, авылдан да килгәннәр. Коронавирус инфекциясе таралуга юл куймау максатында билетлар залның 70 процентына гына сатылган иде. Шул рәвешле тамашачыга социаль дистанция саклау мөмкинлеге тудырылды.

Узган атнада Иске Вәрәш авылында театр карадык. Минзәлә татар дәүләт драма театры артистлары Мәҗит Шамхаловның "Каенана" музыкаль комедиясен күрсәтте. Мәдәният йортына халык битлекләрдән килгән иде. Кергәндә ишек төбендә дезинфекция чарасы белән кулларны эшкәртү мөмкинлеге тудырылды. Халык, дөньясын онытып, комедия карады.

Ярый, барып калганбыз әле. Халыкның иминлекне кайгыртып, мәдәни чараларны үткәрүгә дә чикләүләр кертелгән дип ишеттек. Саклану чараларын күрү кирәк, билгеле. Концерт карамыйча да торып була. Сәламәтлектән аермасын.

**Эльмира Гомәрова,**
**Мөслим гимназиясенең 6а сыйныфы укучысы:**

– Юл йөрү кагыйдәләрен безгә даими өйрәтәләр. Укытучылар да, районның ДАИ хезмәткәрләре дә бу темага кагылышлы төрле тематик чаралар, практикдәресләр үткәрәләр. 5-6 сыйныф укучылары арасында юл хәрәкәте иминлеге буенча бәйге оештырылуын ишеткәч, без дә көчебезне сынап карарга булдык. Республика күләмендә узган интернет-олимпиадада катнашып, белемнәребезне сынадык, яңа кагыйдәләр үзләштердек. Бәйгегә безне гимназиянең башлангыч сыйныф укытучысы Алсу Гомәрова әзерләде.

Онлайн-тест тапшыруда беренче генә катнашуыбыз түгел иде. Мин һәм 5а сыйныфыннан Лилиана Нургалиева, Илзирә Зиннурова, Илһам Гайнуллин иң күп балл җыйдык. Бирелгән сорауларның барысы да юллардагы иминлеккә, юл кагыйдәләренә кагылышлы иде. Бүгенге көндә юллардагы вәзгыять – төп мәсьәләләрнең берсе. Юллар барыбыздан да игътибар сорый. Интернет-олимпиада белемнәребезне тагын да ныгытты. Барыбызга да ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы, ТР юл иминлеге баш дәүләт инспекторлары имзалаган таныклыклар бирелде.

«Авыл утлары»
№ 83 (11335) | **11 ноябрь** 2020 ел



# Киләчәк тормышка әзерлиләр

Түбән Табында сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен интернат-мәктәптә 63 гаиләдән 84 бала белем һәм тәрбия ала.

**Лилия Шәймиева**

**Тарихка күз салсак, Тойгелде интернат-мәктәбе 1971 елда ачылган. Ул елларда биредә 92 бала укыган. 2011 елда мәктәп – Ташлыяр авылына, 2016 елда, капиталь ремонттан соң, Түбән Табын мәктәбе бинасына күчерелә.**



Балаларның кул эшләре./ ЛИЛИЯ ШӘЙМИЕВА ФОТОСЫ.

– Бездә сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балаларга башлангыч һәм төп гомуми белем бирелә. Мәктәптә физик мөмкинлекләре чикләнгән, нигездә, психик үсеше тоткарланган балалар укый. 84 баланың 71е – интернатта яшәп, унбере, сәламәтлек мөмкинлекләреннән чыгып, индивидуаль программа буенча өйдә белем ала. Барлыгы 9 класс-комплект тупланган, – ди мәктәп директоры Илшат Хәбибуллин.

Традицион укыту системасыннан аермалы буларак, бу мәктәптә төп игътибар фәннәрне үзләштерүгә түгел, тормышка әзер кешеләр тәрбияләүгә нигезләнгән.

– Мөмкинлекләре чикле балалар да үзләренең әзерлек дәрәҗәсе, сәләтләре, мөмкинлекләре буенча да төрле. Дәрестән тыш эшчәнлеккә зур игътибар бирелә. Әхлак тәрбиясе, социаль, гомумкультура, спорт-сәламәтләндерү юнәлешендә төрле түгәрәкләр үткәрелә. Бу балаларның һәрберсенә аерым якын килеп, үз итеп сөйләшсәң генә, аларның телен дә, күңелен дә аңлап була. Һәм иң мөһиме – алар ихлас ярату кирәк, – ди мәктәп директоры урынбасары Диана Шакирова.

Укучыларны киләчәк тормышка әзерләү – интернат-мәктәпнең төп бурычы. Авыл хуҗалыгы хезмәте, чәчәк үстерү дәресләрендә укучылар терлекчелек һәм үсемлекчелек буенча белем алалар. Игенчелек культураларыннан, җиләк-җимеш һәм яшелчәләрдән мул уңыш алу серләрен өйрәнгән укучыларның күбесе авыл хуҗалыгы тармагында хезмәт куя.

– Хезмәт дәресләрендә ир балалар – агач эшкәртү күнекмәләренә, кызлар тегәргә, бәйләргә өйрәнәләр. Йорт эшләренә өйрәнү дәресләрендә алар аш-су әзерләү, бүлмә бизәү күнекмәләрен үзләштерә, – ди хезмәт укытучысы Айрат Хәсәенов.

Интернат-мәктәптә балаларның буш вакытларын файдалы һәм мавыктыргыч итү максатында ял һәм уен бүлмәләре булдырылган. Бүлмәләр өстәл уеннары, башка уенчыклар, матур әдәбият, кирәкле җиһазлар белән тулыландырылган. Иганәчеләр ярдәме белән ясалган тоз бүлмәсендә (галокамерада) укучылар шәфкать туташлары контролендә сәламәтлекләрен ныгыталар.

– Эти-әниләр белән эшләүгә дә зур игътибар бирәбез. Аларның мәктәп тормышында актив катнашуы мөһим. Ата-аналар җыелышларыннан тыш, эти-әниләр белән берлектә бәйрәмнәр, спорт чаралары үткәрәбез. “Тату сыйныф серләре” республика конкурсында дүрт ел рәттән актив катнашып, призлы урыннар яуладык. Укучылар республикакүләм махсус олимпиадада, өстәл теннисы, армрестлинг, мини футбол ярышларында актив катнашып, яхшы нәтиҗәләргә ирешәләр. 2017 елдан “Шифа” балалар сәламәтләндерү лагере эшли, – ди Илшат Хәбибуллин.

Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балаларга хезмәт тәрбиясе бирү – игътибар үзәгендә. Экологик акцияләр, өмәләр үткәрәләр, мәктәп яны, сугышта һәлак булганнар истәлегенә күтәрелгән обелиск территорияләрен чистарталар. “Игелекле йөрәкләр” отряды волонтерлары составында Түбән Табын авылында яшәүче өлкәннәргә ярдәм итәләр.

Мәктәпне тәмамлаучылар арасында Түбән Кама, Азнакай, Әлмәт шәһәрләрендә, Бакалыда урнашкан һөнәри уку йортларына укырга керүчеләр бар. Алар, укуларын тәмамлагач, үзләренең туган якларына яки башка шәһәрләргә китеп, эшкә урнаша.

# “Офык”тан якты киләчәккә – бер адым

**Лилия Шәймиева**

**“Офык” мәктәптән тыш эшләр үзәге – районда балаларга өстәмә белем бирүче өч оешманың берсе. Балаларның иң яраткан берләшмәләренең берсе – робототехника.**



“Техник модельләштерү” түгәрәгендә./ ЛИЛИЯ ШӘЙМИЕВА ФОТОСЫ.

Монда нигездә башлангыч класс укучылары шөгыльләнә. LEGO (лего) роботлардан төрле конструкцияләр җыю мавыктыргыч уен кебек тоелса да, башны эшләтергә дә, вак кына детальләрне дөрес итеп җыярга да кирәк. Укучылар, гади конструкцияләрдән башлап, командаларны блок ярдәмендә үтәүче “акыллы” роботларга кадәр җыялар. Бүген алар датчиклар ярдәмендә төсләрне аера һәм каршылык алдында туктап кала торган конструкцияләр ясау белән мәшгуль.

– Берләшмәләр эшчәнлеген штаттагы педагоглар алып бара. Бүгенге көндә бездә 12 кеше эшли. Коллективка яшь, яңа педагоглар һәм белгечләр кабул итәк. Алар яңа юнәлешләр буенча эшли. План нигезендә без 259 балага өстәмә белем бирергә тиеш. Берләшмәләргә 80 процентка якын бала җыя алдык. Укучыларга дәрестән тыш вакытларын файдалы уздыру өчен бөтен мөмкинлекләр тудырылган. Тәнәфес вакытында тамак ялгап алу, ял итү урыннары бар. Балаларын алырга килгән эти-әниләр телевизор аша оешманың эшчәнлеге белән таныша ала, – ди мәктәптән тыш эшләр үзәге җитәкчесе Аяз Бәдретдинов.

“Техник модельләштерү” түгәрәген башлангыч класс малайлары үз итә. Программа нигезендә ракета, авиа, авто, судомодельләштерү серләренә өйрәнәләр. Гап-гади кәгазьдән башлап, юка плитка, картон, фанерадан да төрле модельләр ясыйлар.

– “Инженерлык лабораториясе” берләшмәсенә йөрүчеләр фрезер станогында агачтан төрле модельләр, брелоклар ясарга, әзер материалга истәлек язулары төшерергә ярата. 3D принтерда махсус пластиктан сувенирлар, макетлар ясыйлар, укучылар эретеп ябыштыру аппаратында эшләргә дә өйрәнә. Балаларда лазер станогы аеруча кызыксыну уята. Монда фанерны, органик пыяланы кисеп, төрле макетлар, көнкүреш җиһазлары ясыйбыз. Әлеге станок гравировка да ясый ала. Кабинет проектор, экран белән җиһазландырылган, – ди берләшмә җитәкчесе Илшат Закиров.

Кыз балаларны “Иҗат студиясе” җәлеп итә. Монда алар гади генә конструкцияләрне күзалларга, кайчы, җилем белән эшләргә, энә тотарга, бизәргә өйрәнәләр. Берләшмә җитәкчесе Ания Митрофанова сүзләренә караганда, алар төсле кәгазь, фоамиран, фетр, җҗут, гипс, цемент кебек материаллардан сувенирлар, кул эшләнмәләре ясыйлар. Тегү-чигүгә дә өйрәнәләр. Көндәлек тормышта кирәк булырдай аксессуарлар ясау да кызыксындыра икән кызларны.

Күп эти-әниләр балаларын инглиз телен тирәнтен өйрәнү максатында оештырылган “English club” (Инглиш клаб) берләшмәсенә (инглиз клубы җитәкчесе – Эльза Шаймәрданова) йөртүне өстен күрә. Берләшмәгә нигездә башлангыч класс укучылары йөри.

Балаларның иң яраткан гаджетлары – компьютер һәм кәрәзле телефон. Шушы кызыксынуны истә тотып, яңа уку елыннан “Блогер 2.0” дип исемләнгән берләшмә эшли башлаган. Балалар мәктәптә, өйдә алган мәгълүматны интернет аша таратырга өйрәнәләр. “Хәзерге заманда үзләрен блогер ролендә күрү иптәшләре алдында үзенә күрә бер дәрәҗә, горурлык санала. Бәлки, киләчәктә кемдер үзен шушы өлкәдә табар”, – ди үзәк белгечләре.

5-8 класс кызлары “HandMade” (Хенд Мейд) берләшмәсенә яратып йөриләр. Бу – алда әйтеп үтелгән “Иҗат студиясе”нең дәвамы. Укучылар, төрле сувенирлар, өйне бизәү өчен әйберләр, кәгазьдән үрелгән кәрзиннәр, вазалар һ.б. кирәк-яраклар ясап, аларны социаль челтәрләрдә “Блогер 2.0” түгәрәгендә ясалган төркемнәр аша интернет-кибетләрдә сату белән шөгыльләнә.

– Район, республикакүләм бәйгеләрдә катнашып, призлы урыннар яуладык. Робототехника түгәрәгендә шөгыльләнүчеләр Мамадышта узган “Техно-игры 2.0” фәнни-техник квестта икенче урынга лаек булды. Яшь фотосөючеләр “Юность России” Бөтенроссия бәйгесенең республика этабында “Макро” һәм “Анималистика” номинацияләрендә – икенче, “Репортаж” номинациясендә өченче урынны яуладылар. “XXI гасыр яшь техниклары” конкурсының республика турында “Техник модельләштерү” һәм “Робототехника” номинацияләрендә өченче урынны алдылар, – ди Аяз Бәдретдинов.

Сәләтсез бала булмый, бары тик аның белән эшләргә, аңа үз вакытында ярдәм итәргә генә кирәк. Үзәктә алган белем балаларга киләчәктә һөнәр сайларга, тормышта үз юлларын табарга ярдәм итәр, шәт.

# Өлкәннәрдән үрнәк алыйк!

Өлкәннәрнең үҗәтлеге, бетмәс оптимизмы сокландыра. Безгә дә алардан үрнәк аласы иде.

**Лилия Шәймиева**

**Сәламәт яшәү рәвеше алып бару өчен Мөслимдә бөтен мөмкинлекләр тудырылган. Шәһәрләр кызыгырлык яңа бассейн ачылу да – моның ачык мисалы. "Тамчы" бассейнында беренче бәйге балалар арасында узган иде. Анда Мөслим, Мамадыш, Сарман районнарыннан барлыгы 120 спортчы катнашты. Алар 25, 50, 100 метр арада брасс һәм баттерфляй алымы белән йөзделәр.**

– Бәйгедә 8 яшьлек оныгым катнаша. Башта ул "Нептун" бассейнына йөргән иде, яңасы ачылгач, монысына йөри башлады. Биредәге уңайлыкларга шаккатам, – ди оныгы өчен җан атарга дип Үрәзмәттән үк килгән Флүсә апа Фатыйхова.

Шәхси зачетта 23 комплект медаль уйнатылды. Ярышлар барышында 9 спортчы – өченче, 7 спортчы – икенче һәм 5 спортчы беренче яшүсмерләр разряды нормативларын үтәде. Призлы урыннарның барысын да диярлек мөслимлеләр яулады. Катнаш эстафетада да район командасына тиңнәр булмады. Шулай итеп, Мөслим командасы бүләкләре 21 алтын, 17 көмеш, 18 бронза медале белән тулыланды.

– Балалар кечкенәдән үк спортка тартыла. Бу – районыбыз өчен зур сөенеч. Спорт түгәрәкләренә, секцияләргә йөрүчеләр саны арта. Сәламәт яшәү рәвеше сайлаганнар рух ныклыгы белән аерылып тора, – ди спорт мәктәбе тренер-укытучысы Илдар Мадьяров.

"Тамчы" йөзү бассейнында узган атнада өлкәннәр арасында ярышлар үтте. "Өченче буын" республика ярышларының муниципаль турында катнашучылар саны шактый иде.

– Өлкәннәр – җирлегебезнең тиңсез хәзинәсе. Бер генә чара да алар катнашыннан башка узмый. Алар актив тормыш позициясе белән яшьләргә үрнәк булып тора, – ди район Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль-мәдәни мәсьәләләр буенча урынбасары Марина Бәдретдинова.

– "Тамчы" бассейны су объектлары төзелеше буенча Президент программасы нигезендә сафка басты. Бассейннан кеше өзелми. Өлкән буын да бик теләп йөри, спорт белән шөгыльләнә. Алга таба өлкәннәрне спортка тагын да күбрәк җәлеп итәргә ниятлибез. Моның өчен бездә бөтен мөмкинлекләр дә бар, матди-техник базабыз да бай, – ди район яшьләр белән эшләү һәм спорт бүлеге җитәкчесе Илшат Яббаров.



Равил Сәхбиев, Валерий Кондратьев, Таһир Шәйхразиев./ АЙРАТ ФАЗЫЛОВ ФОТОСЫ.

Бәйгедә ир-атлар арасында беренче урынны Яңа Усы авылыннан Валерий Кондратьев яулады. Икенче урында – Мөслимнән Таһир Шәйхразиев, өченчедә – Мәлләтамактан Равил Сәхбиев. Хатын-кызлар арасында Вәрәшбаш авыл җирлегеннән Рәйсә Хаметовага тиңнәр булмады. Мәлләтамактан Галия Вагыйзова – икенче, Олы Чакмактан Сирена Фәсхиева өченче урынны алды. Беренче урынны алучылар башкалада узачак ярышларда Мөслим данын яклаячак.

– Спорт белән шөгыльләнү чыныктыра, сәламәтлекне ныгыта. Сәламәт яшәү рәвеше алып бару – минем тормыш позициям. Алга таба да спорт чараларында катнашырга язсын, – ди Рәйсә Хаметова.

# Спортка мәхәббәте дә озын гомерле

**Лилия Шәймиева**

**Ташкентта туа Галия. Аларга якын гына аккан Хан елгасы тирән һәм бормалы булуы белән аерылып тора. Курыкмаган да инде күрше абыйлары! Йөзәргә өйрәнсен өчен 6 яшьлек Галиянең биленә бау бәйләп елга уртасына ыргыта торган булганнар.**

Сабый нишләсен инде?! Чәбәләнә-чәбәләнә йөзәргә өйрәнә. Беренче Мактау грамотасын 11 яшендә Ташкент шәһәренең "Огонек" лагеренда ала. Өендә Мактау грамоталары һәм медальләрнең исәбе юк. Аларның барысын да кадерләп саклый ул.

– Мин спортны бик тә яратам. Спорт сумкамны алдан ук әзерләп куям. Иртәгә ярышка диган төндә, йокламыйча, борчылып чыгам. Спорт дөньясында мин үземне судагы балык кебек хис итәм. Тәндә – тазалык, йөрәктә – егәр, беләктә көч булсын дисәң, бертуктамый шөгыльләнү кирәк, – ди Галия апа.

Бүгенге көндә Мәлләтамак авылында яши Ташкент кызы. 21 яшендә Иске Вәрәш авылына кунакка кайтан кыз Мәлләтамак егетенә гашыйк була. Нәҗип тә кунак кызына битараф булмый. Армиягә киткәч, өч ел хат язышалар. Германиядән килгән хатларны Галия түземсезләнеп көтеп ала. Ә бер кунакка кайтуында Нәҗип кызга тәкъдим ясый. Яшьләр, озакка сузмыйча, туй да итәләр. "Балдаклар алышмасак та, туй күлмәкләре кимәсәк тә, Аллага шөкер, никахыбыз озын гомерле булды", – ди Галия апа.

Спортка булган мәхәббәте дә озын гомерле аның. Җиденче дистәсенә якынлашып килүче Галия апа Вагыйзова ярышлардан кайтып та керми диярлек. Күптән түгел генә бөтенроссия ярышларында булып кайткан. 200 спортчы арасында беренче бишлеккә кергән ул.



Галия Вагыйзова./ ЛИЛИЯ ШӘЙМИЕВА ФОТОСЫ.

– Бу медальләр һәм Мактау грамоталары юкка гына бирелмәде. Аларны яулап алырга кирәк бит әле! Җиңүләр җиңел бирелми. "Өченче буын" республика ярышларының муниципаль этабында да, өлкәннәр арасында узган йөзү бәйгесендә дә икенче урынга лаек булдым, – ди Галия Вагыйзова.

Йөзү буенча гына түгел, волейбол, шахмат-шашка, дартс, йөгерү ярышларында да теләп катнаша ул. Үзешчән сәнгатьтә дә актив. Авыл үзешчәннәре концертларында үзбәк биюе белән чыгыш ясый. Аш-суга да оста. Ара ерак дип тормый – бертуганы янына Грециягә кадәр барып, кунак булып кайта.

– Җирлегебездә актив тормыш алып баручы пенсионерлар күп. Алар ярышларга да, башка төрле чараларга да бик теләп йөриләр. Ялындыра белмиләр, ярдәмчел, киң күңелле булулары белән аерылып торалар. Галия апа бигрәк тә тәвәккәл, максатчан булуы белән аерылып тора. Арабызда шундый шат күңелле, оптимистик рухлы кешеләр күбрәк булсын иде! – ди Мөслим районында клиентларны кабул итү хезмәте җитәкчесе Фәридә Ганиева.

## Спорт яңалыклары

### Бөтенроссия ярышларында

**Район бадминтончылары уңышлары белән сөендереп кенә тора. Нурислам Шәйхуллин һәм Айнур Җәлилов Түбән Новгород шәһәрендә узган бөтенроссия ярышларында Татарстан Республикасы җыелма командасы составында чыгыш ясады.**

Нурислам 15 яшькә кадәрге спортчылар арасында ялгыз разрядта – беренче, парлы һәм катнаш разрядларда икенче урынны алды. Айнур 17 яшькә кадәрге егетләр арасында ялгыз разрядта – икенче, парлы һәм катнаш разрядларда беренче урынны яулады.

Бәйрәм көннәрендә Байлар Сабасында узган бөтенроссия ярышларыннан да җиңү белән кайтты егетләр. Ялгыз разрядта Айнур һәм Нурисламга тиңнәр булмады. "Ярышта катнашу чыгымнарын шәхси эшмәкәр Фаит Шәймәрзин күтәрде, рәхмәт аңа", – ди егетләрнең тренеры Инсаф Ханов.

### Районара волейбол турниры

**Халыклар бердәмлеге көне уңаеннан "Яшьлек" спорткомплексы кубогына ир-егетләр арасында волейбол турниры узды.**

Бәйгедә барлыгы сигез команда катнашты. Киеренке көрәштә Сарман районы командасы беренче урынны яулады һәм кучмә кубок белән бүләкләнде. Бу – сарманлыларның өченче ел рәттән җиңүләре. Икенче урында – Әлмәт шәһәренең "Система сервис", өченчедә – Мөслимнең "Илтранс" волейболчылары. Командаларга Мактау грамоталары, медальләр тапшырылды.

# Тармакны бергәләп күтәрдек



Гөлсинә Гаязова./ ФОТО – Г. ГАЯЗОВАНЫҢ ГАИЛӘ АРХИВЫННАН.

ТАССРга – 100 ел

**Әткәем Фәтхел белән әнкәем Мәрьям Әлмәт авылында җидешәр балалы гаиләләрдә туганнар. Алар, 1927 елда гаилә корып, бер-бер артлы 5 бала алып кайталар. Мин 1940нчы елның 7 ноябрендә төпчек бала булып туганмын. Әткәем белән әнкәем бала кайгыларын күп кичергән. Биш яшькә җиткәч, ике кызлары һәм бер уллары кызамык белән чирләп үлгән.**

Бөек Ватан сугышы башлангач, әткәебез, аның абыйсы һәм энесе фронтка китәләр. Әткәй киткәндә абыем Рифкатькә – 3 яшь тә 10 ай, миңа 9 ай була. Ел ярым узуга абыем да чәчәк авыруыннан үлә. Миңа ул чорның ачы шулпаларын күп татырга туры килде. Замانасына хас авыр көннәрне әнкәй белән бергә үткәрдек. Ул чорларда законнар да каты иде шул. Хәтердә калганнарын исемә төшерсәм, хәзер дә җаннар өшеп китә.

...Бер көнне кырыклап хатын-кыз, чаналар тартып, Әҗәкүл пристанена чәчүлек орлык алырга киттеләр. Мин берүзем өйдә калдым. Әнкәй бармаска тырышты, ләкин рөхсәт итмәделәр. Өч көн дигәндә кайтып керде мескенкәйләрем. Әнкәемнең чабатасы таралган, табан аслары кабарган, кайткач ун көн чирләп ятты. Басу эшләре иртә таңнан кич караңгы төшкәнче бара иде. Без – балалар, әз булса да тамак ялгарга дип, җәяүләп алар янына барабыз. Өйдә ашарга юк. Әнкәй, үләннәр турап, бәрәңге шулпасы пешерә. Нинди авыр вакытларда да әнкәй сыерны бетермәде, җилкәсендә салам ташып туйдыра иде. Өйдә мичкә ягарга утын юк, салам ташып яга иде әнкәй.

Беркөнне караңгы төшеп килгәндә бишләп хатын, җыелдылар да, Башкортостанның бездән 6-7 км ераклыктагы Үмер урманына утынга дип чыгып киттеләр. Һәрберсе чана, бау, балта алган иде. Яктыра башлагач кайтып җиттеләр. Лесник килеп чыккан да, чаналарын турап ташлаган, бауларын, балталарын алып калган. Утын да юк, чана да. Әнкәйләрнең кайткач елап утырганнары әле дә күз алдында.

Ул чорларда салым түләү күп иде. Акча юк, ә түләү мәҗбүри. Безнең сыерның сөте күп. Әнкәй, эштән кайткач, төнлә сепарат аертырга китәбез. Авылда бер сепарат кына бар. Анда халык шыгрым тулы, чиратың җиткәнче төнге сәгать берләр җитә иде. Әнкәйне кечтеп, почмакта йоклап китәм. Сөт өсте салынган савытка билге куеп, кар базына төшереп кайтып китәбез. Бер атна узгач, аны барып язабыз, гарсасын сепарат тоткан кешегә калдырыш. Маен алып кайткач, төнлә, 5-6 хатын берләшеп, авылдан 25 км ераклыктагы Бакалы базарына чыгып китәләр. Инсәләренә көянтә-чиләк аскан хатыннар, таң атканда барып җитеп, майларын саталар. Хәлдән таеп кайтуларына авыл советыннан салым җыючы көтеп тора. Үзебезгә тотарга акча да калмый. Менә шундый авырлыклар күреп, фронт өчен дип эшләде алар.

Сугыш бетте. Башкалар кебек әткәй кайтканны көтәбез. Авылга солдат кайткан саен, әткәйне күрмәделәр микән дип, мин дә йөгереп барам яннарына. "Юк шул, күрмәдек. Юлда кеше күп, кайтыр ул, көтегез" – дип юатып чыгардылар.

Юк шул, әткәй кайтмады. Аның "үлде" хәбәре 1942 елның августында ук килгән булган. Әнкәй бу хакта 8 яшем тулгач кына әйтте. Аннан өмет өзелде инде, кабат-кабат әнкәйдән сорап җәфаламадым. Безнең гаиләдән әткәй, аның абыйсы, энесе һәм әнкәйнең ике энесе сугыштан кайтмады.

1948 елда әнкәй, картайды дип, сыерыбызны суйдырды да итен Әмәкәй базарына илтеп сатты. Төштән соң "акча алышынган" дигән хәбәр таралган. Әнкәйнең: "Сыерсыз да, акчасыз да калдык", – дип елап кайтып кергәне истә.

Мәктәпкә 8 яшем тулгач кердем. Язарга дәфтәр юк, китап битләренә язып хәреф өйрәндек. Кара да юк. Әнкәй үзе ясап бирә иде. Өскә кием юк, аякта – юкәдән ясалган чабата. Яз көне, су үтмәсен дип, чабатага агачтан күтәртмә беркетеп бирәләр. Кышкы салкыннарда, буранлы көннәрдә башка одеял ябынып йөргәнем истә.

1952 елда, әнкәйнең әти-әниләрен карарга дип, Әмәкәйгә күчендек. Мин Әмәкәй мәктәбенә укырга кердем. 1955 елда 7 классны тәмамлагач, Күбәк урта мәктәбенә 12 километр җәяү йөреп, өч ел укыдым. Ул чорда акча юк. Әткәй фронтта үлгәнгә 8 сум акча түлиләр. Шулай да, хыялларның биекләренә үрелмичә, авыл тормышына якынын сайлап, Минзәлә авыл хуҗалыгы техникумының зоотехниклар әзерләүче бүлегенә кердем. Белгечлек алгач, 1961 елның февралендә юллама белән үзебезнең районга эшкә кайттым.

Ул вакытта райком секретаре – Мәгъсүм Хөсәенов, район Советы башкарма комитеты рәисе – Тимерхан Борханов, авыл хуҗалыгы идарәсе җитәкчесе – Василий Герасимов, баш зоотехник Евгений Иванцов иде. Мине юллама белән Тукай исемендәге колхозга баш зоотехник итеп җибәрделәр. Алты авылны берләштергән зур хуҗалык, торaклар сәмән кирпеченнән төзелгән, һәр авылда бөтен төр терлек асрала. Сөтчелек фермалары өч урында. Мөгезле эре терлекләр алты авылда да бар иде. Сарыкчылык һәм дуңгызчылык – ике авылда, бер авылда куян фермасы урнашкан. Бөтен эш кулдан башкарыла. Терлекчелектә дә, игенчелектә дә түләү – хезмәт көненә, акчалата түләү кертелмәгән. Хезмәт көненә урак беткәч икмәк бирелә. Миңа айга 140 хезмәт көне билгеләнде. Ике ел шушы хезмәт көненә эшләдем. Ике елдан соң терлекчелектә дә, игенчелектә дә хезмәткә акчалата түләү кертелде. Хуҗалыкта эшне нәсел эшен яхшыртудан башладык.

Сыерларның күп сөтлеләрен Кызыл Төбәк фермасына тупладык. Бу фермадагы сыерлардан туган бикәч бозауларны сайлап алып, 6 ай юнәлешле үстереп, Яту фермасына җыйдык. Анда үстереп, каплатканнан соң, кабат Кызыл Төбәккә кайтардык. Бу ферма калган фермаларны буаз таналар белән тулысынча тәэмин итә башлады. Учет эшләрен дә җайга салдык. Сыерлар ясалма юл белән каплатыла башлады.

Азык запасы булдыруга зур әһәмият бирелде. Тукай исемендәге колхоз кукуруз игү буенча илдә дан казанды. Кәшфи абый Рафиков звеносы 3 метр озынлыгында кукурузлар үстерә иде. Аның тәҗрибәсен өйрәнү өчен республика күләмендә семинарлар оештырылды. Басуларда курган ысулы белән ике көн эчендә кукуруз силосы салынды. Азык запасы ел ярымга җитә иде.

Әкренләп терлек торакларын механикалаштыру кертелә башлады. Башта механик юл белән савуга күчтек, су "автопоилкалар" ярдәмендә эчерелә башлады. Терлекчелек продукторларын җитештерү һәм сату планнарын уңышлы үтәдек. Биш ел дәвамында белгеч буларак шактый тәҗрибә тупларга өлгердем.

1966 елда мине районның иң зур совхозы – "Михайловка"га билгеләделәр. Мөгезле эре терлекләр – 3600, савым сыерлары – 750, дуңгызлар – 4600, сарыклар – 3800 баш. Моннан тыш 180 баш ат, 650 баш куян бар. Директоры Вәли Хәлиуллин булган совхозда ике ел зоотехник булып эшләгәннән соң, район авыл хуҗалыгы идарәсе җитәкчесе Акмал Әхмәтшин идарәнең өлкән зоотехнигы итеп чакырды. Бу вазыйфада мин 33 ел эшләдем.

Ул елларда районда 22 колхоз һәм 3 совхоз бар иде. Авыл хуҗалыгы идарәсендә 19 кеше хезмәт куя. Терлекчелек бүлеген тәҗрибәле зоотехник Зәфәр Кадыйров җитәкли. Транспорт Акмал Әхмәтшинда һәм баш агроном Барый Галләмовта гына. Терлекчелек бүлегендә ат бар иде. Шушы ат белән хуҗалыкларга чыгып, иртә таңнан кичкә кадәр фермаларда булып, терлекчеләр белән очрашабыз. Кимчелекләрне төзәтү юлларын күрсәтәбез. Берничәшәр көн авылларда кунып эшли идек.

Мин эшли башлаганда районда сөтчелек фермалары 46 иде. Бер ел эчендә хуҗалыкларда специальләштерү эшләре башкарылды. Мөгезле эре терлек фермалары 45тән 35кә калды. Шуның эченнән 14е нәсел фермалары итеп оештырылды. Таналар үстерү буенча –15, терлек симертү буенча 23 ферма специальләште.

Мирхаҗиян Сәлахов җитәкләгән "Урожай" колхозында, Исәнсеф дуңгызчылык фермасын нәсел фермасы итеп үзгәртеп, район хуҗалыкларына ел саен 600-700 баш ана, 500-600 баш ата дуңгыз саттылар. Артканы республика районнарына сатыла иде. "Кызыл Октябрь" колхозының Мәллләтамак бригадасында да шундый нәсел фермасы оештырылды. Нәселле дуңгызлар республика районнарына сатылды.

Мари Буләрдә сарыкчылык фермасы нәселле итеп оештырылды. "Урожай" колхозы, нәселле атлар алып кайтып, юртаклар, чабыш атлары үстерә башлады. Колхозның даны республикада һәм Россиядә таралды. Ярышларда, сабантуйларда призлы урыннар, зур бүләкләр алдылар.

*(Дәвамы бар).*

**Гөлсинә Гаязова.**
**Мөслим.**

---

# Таләпләр үтәлергә тиеш!

Иминлек

**Татарстан Республикасы буенча Россия авыл хуҗалыгы күзәтчелеге идарәсе терлек һәм кош-кортларда кош гриппы, инфекцияле бронхит, африка чумасы, ящур, бруцеллез, нодуляр дерматит, туберкулез кебек йогышлы авырулар барлыкка килү һәм таралу куркынычы зур булуы турында хәбәр итә.**

Йогышлы авырулар терлек һәм кош-кортны асраганда, реализацияләгәндә гади генә ветеринария таләпләрен үтәмәү сәбәпле килә. Терлекләрне, кош-кортны, терлекчелек продукциясен реализацияләгәндә, күчереп йөрткәндә ветеринария белешмәләре, таныклыклары булырга тиеш. Аларда үткәрелгән вакцинация чаралары, лаборатор тикшерүләр күрсәтелә.

Республика районнарында һәр елны үткәрелүче көзге чаралар башланды. Әлеге чаралар йогышлы авыруларны кисәтүгә, ачыклауга һәм бетерүгә юнәлтелгән. Профилактик вакцинацияләү, кан алу төп чаралар булып тора һәм алар милекнең бөтен төрендәге терлек хуҗалары өчен мәҗбүри. "Ветеринария турында"гы Россия Федерациясе Законының (№4979-1, 14.05.1193 ел) 18 маддәсе нигезендә мал хуҗалары РФ Дәүләт ветеринария хезмәте системасына керүче оешма һәм органнарның вәкаләтле затлары булган ветеринария белгечләренә аларның таләбе буенча терлекләрен күрсәтергә, әлеге белгечләргә терлек, кош-кортның кинәт яисә күпләп үлүе, аларның үз-үзләрен гадәттән тыш тотуы хакында хәбәр итәргә, авыруларны кисәтү буенча үткәрелүче чараларны үтәргә бурычлы.

Үтәмәгән өчен административ җаваплылык каралган.

**Эвелина Лотфуллина,**
**ветеринар чиге контроль бүлеге**
**дәүләт инспекторы.**

# Кайсын сайларга?

Пенсия фонды

**Мөслим районында клиентларны кабул итү хезмәте исегезгә төшерә: 2020нче елның 31 декабренә кадәр һәр эшче-хезмәткәр эш бирүчегә үзенең нинди хезмәт кенәгәсен (кәгазь яки электрон) сайлавы турында язмача гариза бирергә тиеш.**

Бүген хезмәт кенәгәсен алып бару ысулын сайлау хокукы бары тик эшләүче гражданнар өчен генә гамәлдә. Беренче тапкыр 2021нче елның 1 гыйнварыннан соң гына эшли башлаучы гражданнарның мондый хокукы булмаячак. Аларның хезмәт эшчәнлеге турындагы мәгълүмат бары тик электрон формада гына алып барылачак.

Электрон хезмәт кенәгәсенең бик уңайлы булуын билгеләп үтәргә кирәк. Чөнки бу вакытта хезмәткәр үз хезмәт эшчәнлеге хакындагы мәгълүматны бик тиз ала алачак. Электрон хезмәт кенәгәсен теләсә кайсы вакытта күчереп алырга, дәүләт хезмәтләре яисә Россия Пенсия фонды сайтындагы шәхси кабинет ярдәмендә эш бирүчегә электрон почта аша җибәрергә мөмкин.

Моннан тыш электрон хезмәт кенәгәсе югалудан, кәгазь вариантны тутырганда булучы хаталардан сакланган.

**Мөслим районында клиентларны кабул итү хезмәте.**

# Галинадан – бавыр торты

Аш-су

**Яңа Усы авыл җирлеге башлыгы Галина Романова идарә эшләре белән генә түгел, хуҗалык, ашсу эшләре белән дә бик оста җитәкчелек итә. Галина Романовадан сезгә бик тәмле бавыр торты рецептын тәкъдим итәбез.**



Фото – Г. Романованың гаилә архивыннан.

Кирәкле ингредиентлар: 750 грамм чамасы бавыр, уртача зурлыктагы ике суган, бер кишер, ике йомырка, 200 грамм сөт, ярты чәй калагы көпшәкләндергеч (разрыхлитель), тәменчә тоз һәм борыч, 5 аш калагы он, майонез.

Эш тәртибе: бавыр белән бер суганны иттарткыч аша чыгарабыз. Аннары бавырга йомырка, сөт, көпшәкләндергеч, тоз-борыч, он салып коймак куелыгындагы камыр туглыйбыз. Майланган табада уртача зурлыктагы коймаклар пешереп алабыз. Хәзер чират икенче суганга да җитте. Суганны турап, кишерне кыргычтан чыгарып, кыздырып алабыз. Суынгач 1-2 аш калагы майонез салып болгатабыз. Бавыр коймакларын әчлекне ягып, 5-6 катлы итеп торт формасында өябез. Өстен җаның теләгәнчә бизәргә була. Мин өстен укроп, петрушка белән бизим.

Тәмле булсын!

**Рубриканы Лилия Шәймиева алып бара.**

## Котлыйбыз!



Бу көннәрдә районыбызда яшәүче өлкән буын вәкилләре, тыл һәм хезмәт ветераннары **Гобәйдуллина Рәйсә Гобәйдулла кызы** (Мөслим), **Нәҗметдинова Сафия Нәҗметдин кызы** (Дусай) – 90 яшьлек, **Шәрәфетдинова Миңнесәлимә Мәрдан кызы** (Баек) – 85 яшьлек, **Гаязова Гөлсинә Фәтхулла кызы** (Мөслим), **Чернова Капитолина Петровна** (Рус Шуган) – 80 яшьлек, **Гатина Кадрия Харис кызы** (Мәлләтамак), **Зарипова Зәнфирә Әхәт кызы** (Мәлләтамак) – 75 яшьлек, **Абдуллина Роза Солтан кызы** (Мөслим), **Галиева Рәмзия Зөфәр кызы** (Иске Вәрәш) – 70 яшьлек, **Усманова Лилия Заһир кызы** (Мөслим), **Мирхаҗианов Хәлил Хәниф улы** (Иске Карамалы), **Латыйпова Зәнфирә Аксар кызы** (Иске Карамалы) – 65 яшьлек, **Шәвәлиева Роза Хәмит кызы** (Мөслим), **Сабирова Елена Әбелкасыйм кызы** (Мөслим), **Кәрамуллина Суфия Таһир кызы** (Иске Вәрәш), **Хатыйпова Әлфинә Әзһәр кызы** (Мәлләтамак), **Фәткаева Илисә Мисхәт кызы** (Сал. Мухан), **Кыяметдинова Гөлия Гайнетдин кызы** (Түбән Табын), **Кәрамова Зөләйха Салихян кызы** (Иске Карамалы) 60 яшьлек юбилейларын билгеләп үтәләр.

Хөрмәтле юбилярлар! Сезне ихластан истәлекле гомер бәйрәмнәрегез белән тәбриклибез. Сезгә имин тормыш, ныклы сәламәтлек телибез. Якыннарыгызның күңел җылысын, ихтирамын тоеп, кадер-хөрмәттә озын гомер кичерергә язсын. Гаиләләрегездә һәрвакыт муллык һәм бәрәкәт булсын.

**Рамил Муллин,**
**район башлыгы,**
**район Советы рәисе.**
**Илгиз Низамов,**
**район ветераннар советы рәисе.**

## Кышка әзерләнәбез

Бакчачыга

**Көзнең соңгы ае ноябрьдә бакча эшләрен тәмамлау бурычы тора. Беренче чиратта туфрак туңганчы, түтәлләргә тирес, кош тизәге, агач көле кертеп, җирне көрәк тирәнлегендә казып, язга әзерләп куярга кирәк. Дүртбиш елга бер тапкыр туфракка известь кертеп калдыру да файдага гына.**

Теплицадагы туфракның составын яхшырту кирәклеге турында онытмаска кирәк. Әгәр мөмкинлек бар икән, аның түбәсен ачып калдырыгыз. Андагы туфрак яңгыр һәм кар сулары белән сугарыла, составы яхшыра, шул рәвешле җир үз-үзен "чистарта".

Ноябрь ахырларында, туфрак 5-6 сантиметрга кадәр туңганнан соң, утыртылган түтәлләрне һәм участокта үскән күпьеллык үсемлекләрне мулчаләргә кирәк.

Күпьеллык чәчәкләр турында да онытмыйк. Суыклар башланып, җир бераз туңа төшкәч, суганлы чәчәкләрне (гиацинтларны, лилияләрне, сортлы нәркизләрне, лаләләрне) ябу кирәк. Моның өчен алдан әзерләнгән урман яфраклары, пычкы чүбе, торф вагы һ.б. кулланыла. Аларны чәчәк түтәленә 10-15 сантиметр калынлыгында җәеп, өсләренә чыршы, нарат ботаклары ташлагыз. Кышын кар аз төшсә, тирә-яктан кар җыеп, түтәлләр өстенә өеп куярга онытмагыз.

**14 ноябрь**
**"СТРОЙМАРКЕТ-КОЛОР"**
(элеккеге "Форсат" күпләп сату базасы бинасында) **ачыла**.
***500 СУМЛЫК товар алсаң – бүләккә дисконт картасы.**
**Яшьләр урамы, 2б.**
* Тулырак мәгълүматны сатучылардан белешергә.
* Акцияне шәхси эшмәкәр Жилина М.Г. үткәрә. Акцияне үткәрү вакыты – 14-15.11.2020.
Реклама

## Ярдәм кирәк булса

Игътибар!

65 яшьтән узган өлкәннәргә һәм инвалидларга коммуналь түләүләр башкарганда, азык-төлек, дарулар кирәк булганда балаларының, туганнарының, якыннарының ярдәм итүләре сорала. Ялгыз яшәүче өлкәннәр, ярдәм кирәк булганда, 8-939-361-60-33 телефонына һәм "Маяк" халыкка социаль хезмәт күрсәтү үзәгенә 8.00-16.30 сәгатьләрдә (төшке ял – 12.00-13.00) 2-40-88 номеры буенча "кайнар линия" телефонына шалтырата ала. Вируслы авыруларны кисәтү максатында өлкәннәргә җәмәгать урыннарында йөрмәскә киңәш ителә.

## Кыскача

**ДАИ**

5 ноябрь көнне Мөслим – Олы Чакмак юлында "Лада-Гранта" автомобиле шоферы – 1974 елгы ир-ат транспорт белән идарәне югалта. Нәтиҗә аяныч: машина юл читенә төшеп каплана. Авыр тән җәрәхәтләре алган шофер һәм пассажир Яр Чаллы шәһәренең ашыгыч медицина ярдәме хастаханәсенә озатыла. Шоферның исерек килеш 20 октябрь көнне дә тоткарланган булуы хакында хәбәр итә ДАИ инспекторлары.

**Сәламәтлек**

Табиблар районда пневмония белән авыручылар арта баруын хәбәр итә. Әлеге диагноз көненә 8-9 кешегә куела. Бу көннәрдә район үзәк хастаханәсендә үпкә ялкынсынуыннан 25 кеше дәвалана. 83 райондашыбыз өй шартларында дәвалану курслары уза. "Август-Мөслим" җәмгыяте хәйрия ярдәме кысаларында район үзәк хастаханәсенә ике кислород концентраторы сатып алып бирде. "Август-Мөслим" җәмгыятенә һәм аның генераль директоры Александр Усковка халыкның сәламәтлеге турында кайгыртуы һәм катлаулы эпидемиологик хәлдә район сәламәтлек саклавына зур өлеш кертүе өчен чын күңелдән рәхмәт белдерәбез", – ди район үзәк хастаханәсенең баш табибы Рамил Морзаханов.

**Иминлек**

"Мошенниклык очраклары арта. Узган атнада бер райондашыбыз – 1962 елгы хатын-кыз алдарлар кармагына эләкте. "В контакте" социаль челтәрендә ялган бит аша "танышы" аннан акча биреп торуын сорый. Банк картасының мәгълүматларын әйтеп бирү белән, райондашыбызның картасыннан 77 мең 292 сум акчасы юкка чыга. Шул вакытта гына хатын-кыз алданганын аңлап ала. Бүгенге көндә тикшерү эше бара. "Райондашлар, уяу булыгыз! Якыннарыгыз акча сорый икән, иң элек ул кеше белән телефон аша элемтәгә керегез! Банк картасының мәгълүматларын бирәүгә дә хәбәр итәргә ярамый, алар бары тик сезнең өчен генә билгеле булырга тиеш!" – ди район эчке эшләр бүлегенең җинаятьләрне эзләү бүлекчәсе җитәкчесе Булат Җамалиев.

**www.muslumirc.ru**
**Районда барган вакыйгалар белән "Мөслим-информ" сайтыннан танышып бар!**
Реклама 16+

## Үткәннән бер мизгел



Агитатор Фәнисә Гыйлметдинова һәм лекторлар группасы җитәкчесе Хәмит Шәрипов М. Вахитов исемендәге колхозның Түбән Табын бригадасы механизаторы Файсил Гыйлметдинов һәм прицепчы Тавис Рахмановны соңгы яңалыклар белән таныштыра. 1967 ел. Фотоны Мөслимнән Фәнисә Гыйлметдинова тәкъдим итте.

# Котлыйбыз!



Мәгариф хезмәткәрләренең профсоюз оешмалары советы ноябрь аенда үзләренең олуг бәйрәмнәрен билгеләп үтүче юбиляр хезмәттәшләрен котлый.

Хезмәт ветераннары **Нәсифуллина Гөлзирә Галимҗан кызы** (Түбән Табын), **Шәвәлиева Роза Хәмит кызы** ("Карлыгач") – 60 яшьлек, **Әюпова Зирәк Заһит кызы** (Баланны) – 65 яшьлек, **Абдуллина Рәйсә Әскар кызы** (Тойгелде) – 70 яшьлек, **Әхмәтова Резеда Заһит кызы** ("Карлыгач"), **Гатина Кадрия Харис кызы** (Мәлләтамак), **Софин Меркурий Николаевич** (Тат.Шуран) – 75 яшьлек, **Габдрахманова Саһира Хөснетдин кызы** (Сал. Мухан) – 80 яшьлек, **Газизова Рәйсә Вагыйз кызы** (Симәк) – 90 яшьлек, тәрбияче **Демидова Эльвира Петровна** (Яңа Усы) – 50 яшьлек, техник хезмәткәрләр **Насыйрова Сирена Михайловна** (Мари Буләр) – 50 яшьлек, **Фәхерлегаянова Зилә Рәшит кызы** (Баек) – 55 яшьлек, **Гайнуллин Расил Шәфыйк улы** (Тойгелде) 60 яшьлек юбилейларын бәйрәм итәләр.

Хөрмәтле юбилярларыбыз! Сезгә җан тынычлыгы, чиксез бәхетләр, эшегездә зурдан-зур уңышлар, яхшы, күтәренке кәеф телибез.

# Якташыбыздан – шигъри күчтәнәч

**Мин – Галимова-Шәйдуллина Рузалия Сиражи кызы – тумышым белән Үрәзмәт-Чишмә авылыннан. Бүгенге көндә Казанда яшим. Шигырьләрне кечкенәдән язсам да, беркая да җибәргәнем, бастырганым булмады. "Авыл утлары" газетасына шигырьләремне юллап карамакчы булдым. Алар дөнья күрсә, якташларыма шигъри сәламем булып ирешер иде.**

## Безгә язалар

### САГЫНДЫРА

Балачаклар искә төшә –
Язамын әле тагын.
Һаман да исемдә, авылым,
Һәр тыкрык, һәр урамың.
Бер ваемсыз балачагым
Калды бит минем анда.
Кире кайтмасын да беләм,
Юксындыра шулай да.
Туган авылым бетте инде –
Авылдашлар таралды.
Авыл урманга әйләнде,
Урамнары караңгы.
Их, кайтарасы иде бит
Элеккере чагына.
Атлар, авыл көтүләре
Кайтсын иде тагын да...
Бала-чага шавы белән
Урамнар тулса иде.
Мәктәп, клублар – һәммәсе
Гөр килеп торса иде!

### ГОМЕРЛӘР ҮТӘ ИКӘН

Чәчләргә көмешләр сибеп,
Гомерләр үтә икән.
Күңел картаюны белми,
Нәрсәдер көтә икән.
Яшь, тәҗрибә, акыл арта,
Ә яшьлек китә икән.
Яшь чактагы җиңеллекләр,
Җитезлек бетә икән.
Кайгы-хәсрәткә түзәргә
Сабырлык җитә икән.
Елый-елый, көлә-көлә
Гомерләр үтә икән.

### МАТУР ПАРЛАР

Тәрәзәдән урам күзәткәндә,
Күзем төште чыршы-наратка.
Бер-берсенә матур парлар алар,
Сокланудан туймыйм карап та.
Берсе – егет, берсе – кыз,
Гүя кочаклашып басканнар.
Ботаклары – гүя җылы кочак,
Бер-берсенә сыеныбканнар.
Чыршы кигән озын
матур күлмәк,
Махсус теккән кебек ефәктән.
Нәфис сынын бизи, бик килешле,
Итәк-җиңе – бала итәктән.
Наратына карап сокланамын,
Бөдрә чәче бик тә килешә.
Кәүсәләре шундый чиста-пөхтә,
Ошап тора ыспай егеткә.
Берсен-берсе ничә еллар буе
Саклый алар җилдән, буранннан.
Сокланмыйча үтә алмый кебек
Йөргән кеше шушы урамнан.

### КЫШ

Кышларның бар үзгә,
сихри яме –
Күбәләктәй очып карлар ява...
Дөнья әкияти ап-ак мамык –
Өйгә керәсе дә килми,
рәхәт һава!
Кышларның да була бик зәһәре,
Очкан җирдән кошлар
өшеп төшә.
Бураннары, салкыннары белән
Бар җиһанны сыный ул үзенчә.
Кыш тылсымга ия. Тәрәзләргә
Ясый хыял җитмәс гүзәл бизәк.
Тәндә куәт арта, керсәң әгәр,
Тирләп пешеп, тыштa
карлар көрәп.
Шаяра да, буран тынып тора
Карлар өйгәч тигез урамнарга.
Кышлар усал, тик
куркыныч түгел
Үз учагы, йорты булганнарга.

**Рузалия Галимова-Шәйдуллина.**
**Үрәзмәт-Чишмә –**
**Казан.**




Реклама

**Требуются**
**– управляющий СП Мазино Малая,**
**– специалист по охране труда,**
**–инженер (сельхозтехника),**
**– инженер-механик,**
**– агроном.**
**Телефон 89172227288**
AhmetzyanovaLK@Chelny-hleb.ru
Реклама

*Мөселманнар һәм христианнар өчен ритуаль товарлар.*
*Хафизов ур., 6.*
Т.8-986-712-91-66, 8-917-935-56-38.
Реклама

**ХӘТЕР ТАШЛАРЫ, ЧАРДУГАННАР.**
**Фәтхуллин ур., 6.** Ялсыз эшлибез.
**Т.2-38-46, 8-927-451-27-10.** Реклама


**НАЛИЧНИКИ**
из цветного металла
от **2000** руб.
Широкий ассортимент.
**КОЛПАКИ, ПАРАПЕТЫ, ДОБОРНЫЕ ЭЛЕМЕНТЫ, ВОДОСТОЧНЫЕ СИСТЕМЫ и др.**
***Замеры бесплатные!***
Реклама
Тел.:**89375283405, 89375222132**

**ОЧКИ ОПТИЧЕСКИЕ**
**± 0,5 до ±10,0**
*«Магнит», 2 этаж.*
ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ. НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТА.
Реклама

**ПЛАСТИК ТӘРӘЗӘЛӘР ИШЕКЛӘР**
**Т.8-953-480-00-75**
**Заводта ясала**
Реклама

Покупаем **ДОРОГО** старые **перины, подушки, пух,перо** в любом виде.
**Рога (лося, оленя)**
**Т.8(920)446-47-41**
Реклама

**ТОЛЬКО 13 НОЯБРЯ!!! ВЫСТАВКА-ПРОДАЖА!!!**
***ОБУВИ!! ГОЛОВНЫХ УБОРОВ!!!***
****Обувь мужская и женская!!! Осень, зима от 1000 руб.!!!***
**** Натуральная кожа!!! Экокожа!!!***
****Шапки! Мужские, женские, детские!!! Вязаные от 100 руб.!!!***
**** Меховые шапки!!!***
***Мутон, норка, нерпа, ондатра, кролик, енот!!!***
*Отличного качества, по приемлемым ценам!!!*
*Производство Россия!!!*
**г. УФА!!!**
**Работаем с 9:00 до 18:00 ч. с. Муслюмово, ул. Садовая, 60.**
***Бывший магазин ветеранов!!!***
***Оптика+/- очки для зрения***
ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ. НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТА.
Реклама


## Реклама

### Сатыла

#### терлек

- **Өч бозаулаган сыер.** Т.8-937-599-59-28, 3-18-12.
- **Каплатылган яшь кәҗәләр.** Т.8-919-685-40-23.
- **Бозаулар.** Т.8-960-079-78-44, 8-937-777-20-88.
- **1 бозаулаган сыер,** буаз тана. Т.8-987-189-68-27.

#### төзелеш материаллары

- **Теплицы. Беседки. Козырьки.** Т.8-917-257-14-07.

#### транспорт

- **ВАЗ-2105, 2004 елгы,** запас арткы мост, двигатель. Т.8-908-340-60-55.

#### төрлесеннән

- **Мунча ташы.** Т.8-939-333-72-86.
- **Буаз сыер** сугымлыкка алыштырыла. Т.8-917-255-06-10.
- **Дрова, срубы.** Т.8-937-774-01-78, 8-960-079-65-13.

### Хезмәт күрсәтәбез

- **Грузоперевозки "Газель".** Т.2-37-55, 8-939-388-97-85.
- **Газификация** жилых домов и бань. Т.8-950-318-95-27.
- **Натяжные потолки.** Фаиль. Т.8-987-210-89-88.
- **Окна. Ворота. Двери.** Балконы. Т.8-937-774-37-37.
- **Ремонт телевизоров.** Т.8-950-324-08-91.
- **Ремонт холодильников.** Т.8-951-067-74-13.
- **Оказываем услуги** по строительству коммуникаций методом горизонтально-направленного прокола (ГНП) (газопроводы, системы теплоснабжения, водопроводы, канализация, кабельные линии, линии связи), по устройству переходов под дорогами, ж/д насыпями, естественными водными преградами и т.д. Работа по городу и краю! Т.8-937-294-06-68, 8-908-332-77-36.

### Сатып алам

- **КРС мясом.** Т.8-917-435-41-04.
- **Терелай мал.** Т.8-987-049-73-71.
- **Кыйммәт бәядән** мөгезле эре терлек тиреләре җыябыз. Яр Чаллы шәһәре Түбән Суыксу авылы. Т.8-917-270-73-06.
- **Сыер ите.** Т.8-963-135-33-71.
- **Үгез, сыер ите.** Т.8-927-966-55-53.
- **Сыер, үгез:** итләтә, терелай. Т.8-987-135-03-47, 8-927-940-31-01.

## Белдерү

### Эшкә

- **ИП Хәмадишинга сугым цехына** эшчеләр кирәк. Авыллардан транспорт белән йөртү мөмкинлеге бар. Т.8-917-397-15-81.

**"Мөслим-информ"га татар һәм рус телләрен яхшы белүче корреспондентлар кирәк. Т. 2-55-00, 8-9172785533.** Реклама

Мәллләтамак урта мәктәбенең 1981 елгы чыгарылыш класс укучылары, әнисе **Хәбибуллина Ләйсирә Мотыйгулла кызы** вафат булу сәбәпле, классташлары Данил Хәбибуллинның, туганнарының авыр кайгысын уртаклашалар. Бу кайгыны кичерүдә сабырлык һәм түземлек телиләр.

***

"Агромастер" җитештерү компаниясе коллективы, **әнисе** вафат булу сәбәпле, хезмәттәшләре Данил Хәбибуллинның, туганнарының, якыннарының тирән кайгысын уртаклаша. Бу авыр кайгыны кичерүдә сабырлык тели.

***

Мөслим үзәк хастаханәсе коллективы һәм профсоюз комитеты, әнисе **Җиһаншина Васила Галялетдин кызы** вафат булу сәбәпле, хезмәттәшләре Зилә Маннанованың, туганнарының авыр кайгысын уртаклаша. Бу кайгыны кичерүдә сабырлык тели.

***

Мөслим үзәк хастаханәсе коллективы һәм профсоюз комитеты, әтисе, тормыш иптәше **Гыйльфанов Әнвәр Сәрвәр улы** вафат булу сәбәпле, хезмәттәшләре – шәфкать туташы Фәридә Могътәсимованың һәм элеккеге хезмәттәшләре – Иске Вәрәш фельдшер-акушерлык пункты шәфкать туташы Сөгъдә Мусинаның, туганнарының авыр кайгысын уртаклаша. Бу кайгыны кичерүдә сабырлык тели.

**Гамәлгә куючы: "ТАТМЕДИА" АҖ.**

**www.muslumirc.ru**

**Реклама хезмәте телефоны: (85556) 2-43-05.**

Авыл утлары
Мөслим районы газетасы
"ТАТМЕДИА" АҖ филиалы директоры – баш редактор **Р. Р. Афзалова.** Тел.: 2-55-00.

**Редакция адресы:** 423970, Татарстан, Мөслим районы, Мөслим авылы, Пушкин ур., 43.
**Электрон адрес:** muslimau@rambler.ru
**Телефоннар:** бухгалтерия – 2-39-76, реклама, заказлар – 2-43-05.
**Газетаның оештыручысы һәм нәшире:** "ТАТМЕДИА" АҖ. 420097, Казан шәһәре, Академическая ур., 2.

Газета элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникация сферасында күзәтчелек буенча Федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсендә ПИ №ТУ16-01027 номерлы таныклык белән 2013 нче елның 16 маенда теркәлде.
Газета "Глагол" ҖЧҖ басылды.
Адресы: 423800, ТР, Яр Чаллы шәһәре, Әлмәт тракты, 10 йорт, 3 бина.
Басарга кул куелды 10.11.2020, график буенча – 19.00, фактта – 16.40.
«Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

ТАТ МЕДИА
**Тираж – 2303 данә.**

Редакция фикере һәрвакытта да авторлар фикере белән аваздаш булмаска мөмкин.
Редакциянең рәсми оешмаларда яклаучы булу мөмкинлеге юк.
**Кульязмаларга бәяләмә язылмый һәм алар кире кайтарылмый.**
Реклама-игъланнардагы мәгълүматның дөреслеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы.

© Материаллар редакциянең язма рөхсәте белән генә күчереп бастырылырга мөмкин.

Газета татар телендә атнага ике тапкыр – чәршәмбе һәм җомга көннәрендә, рус телендә атнага бер тапкыр – җомга көнне чыга.
Заказ №2301.
Язылу индексы – П9418.
Бәясе ирекле.
16+